РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 7 ноябре № 39

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә туры китереп, Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә, җир салымы нормаларын билгеләп, җир салымын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

1.1. Җир кишәрлекләренә карата 0,01 процент:

1.1.1. электр тапшыру линиясенең сак зонасы биләгән;

1.1.2. санитар-яклау зонасы биләгән;

1.2. сәнәгать җирләренә һәм башка махсус билгеләнештәге җирләргә караган, 1-3 категорияле гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын төзү һәм файдалану өчен бирелгән участокларга карата 0,05 процент;

1.3. Җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент:

1.3.1. физик затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелешеннән тыш, аларда торак төзелешен гамәлгә ашыру шартларында физик һәм юридик затлар тарафыннан милеккә сатып алынган (бирелгән);

1.3.2. шифаханә-курорт оешмалары биләгән;

1.4. аттракционнар биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,13 процент;

1.5. автомәктәп полигоннары һәм автодромнары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,2 процент;

1.6. шәһәр электр транспорты корылмалары һәм коммуникацияләре биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,22 процент (трамвай һәм троллейбус парклары, депо, шәһәр электр транспортына хезмәт күрсәтү һәм эшләү өчен кирәкле җитештерү һәм ремонт остаханәләре һәм башка объектлар);

1.7. Җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент:

1.7.1. авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яки җирлекләрдә авыл хуҗалыгы кулланылышындагы зоналар составындагы һәм авыл хуҗалыгы тармагы өчен файдаланыла торган җирләргә караган;

1.7.2. торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләрдән тыш);

1.7.3. эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шәхси торак төзелеше, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән), шулай ук «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре;

1.7.4. оборонаны, куркынычсызлыкны һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән;

1.8. биналар, төзелмәләр һәм физкультура-спорт учреждениеләре корылмалары (шул исәптән спорт мәктәпләре) урнашкан җир кишәрлекләренә карата 0,7 процент;

1.9. автостоянкалар биләгән җир кишәрлекләренә карата 1 процент;

1.10. Башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 процент.

2. Рөхсәт ителгән файдалануның бер төреннән күбрәк җир кишәрлегенә карата әлеге җир кишәрлегенә билгеләнгән кадастр бәясе (салым базасы) туры килгән җир кишәрлегенең файдалану рөхсәт ителгән шул төренә карата билгеләнгән салым нормасын кулланырга кирәклеген билгеләргә.

3. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры булып календарь елның беренче, икенче һәм өченче кварталлары санала дип билгеләргә.

4. Салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан салым түләү, беренче, икенче, өченче квартал үткәннән соң хисап чорыннан соң икенче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, җир кишәрлегенең кадастр бәясе процент өлешенең тиешле салым нормасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла. Салым чоры нәтиҗәләре буенча салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килгән елның 5 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

5. Салым ташламаларын бирергә:

5.1. шәхси ярдәмче хуҗалык һәм шәхси торак төзелеше өчен бирелгән һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата җир салымын түләүдән (өлешләрдән) азат итү рәвешендә түбәндәге категория салым түләүчеләр - физик затларга:

5.1.1. Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына, Дан орденының тулы кавалерларына;

5.1.2. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидларына, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидларына;

5.1.3. I һәм II группа инвалидлык инвалидларына;

5.1.4. балачактан инвалидларга, инвалид балаларга;

5.1.5. «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Маяк» житештерү берләшмәсендә 1957 елда авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар ташлау аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулар аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм алуга хокуклы физик затларга;

5.1.6. аеручa куркыныч янаган бүлекчәләр составында атом-төш һәм термоядер коралын сынауда, корал чараларында һәм хәрби обектлардагы атом-төш установкаларда аварияләрне бетерүдә турыдан-туры катнашкан физик затларга;

5.1.7. төрле атом-төш установкаларының төрле төрләре белән бәйле сынаулар, өйрәнүләр һәм башка эшләр нәтиҗәсендә, атом-төш коралын һәм космик техниканы да кертеп, нур авыруын алган яки кичергән яисә инвалид булган физик затларга;

5.2. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

5.2.1. оешмаларга - гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата;

5.2.2. 2011 елның 18 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга индивидуаль торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт яны җир кишәрлеге) алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен бушлай бирелгән җирләрдән файдаланган өчен;

5.2.3. әлеге карарның 5.2.2 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларына 2011 елның 18 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә бирелгән индивидуаль торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт яны җир кишәрлеге) алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен бушлай бирелгән җирләрдән файдаланган өчен;

5.2.4. индустриаль (сәнәгать) парклары һәм сәнәгать технопарклары;

5.2.5. «Түбән Кама» алгарышлы социаль-икътисади үсеш территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешү кысаларында инвестиция проектын тормышка ашыру өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата оешмалар-резидентларга резидентлар реестрына тиешле язуны кертү датасыннан алып, 10 елга кадәр срокка.

6. Әлеге карар белән билгеләнгән салым ташламаларының, карарның 5.2.4, 5.2.5 пунктларында каралган очраклардан тыш, арендага (файдалануга) бирелә торган җир кишәрлекләренә (өлешләргә, кисәкләргә) кагылмавын билгеләргә.

7. Әлеге карарның 4 пунктының гамәлдә булу вакытын 2020 елның 31 декабренә кадәр билгеләргә.

8. Түбән Кама шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 30 номерлы карарын (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин